| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
| 29.01.2026 | № 94 |

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) өченче хәвеф-хәтәр категориясенә кертелгән террорчылыкка каршы яклануын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләрнең җирле бюджет акчалары исәбеннән аларны 2026 елга хосусый саклау оешмаларыннан сатып алуларны гамәлгә ашырганда арттыру турында» 2025 елның 26 декабрендәге 1527 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Терроризмга каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы объектларының (территорияләренең) һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы эшчәнлеге өлкәсенә караган объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан саклануына таләпләрне һәм бу объектларның (территорияләрнең) иминлек паспорты рәвешләрен раслау турында»Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 02 августындагы 1006 номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) хосусый сак оешмаларыннан сатып алуларны гамәлгә ашырганда террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр бәясе нормативларын раслау һәм 12 сәгатьлек эш режимындагы сак постлары санын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 23 ноябрендәге 1114 номерлы карарына таянып», «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) хосусый саклау оешмаларыннан сатып алуларны гамәлгә ашырганда террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле хезмәт күрсәтүләр бәясе нормативларын билгеләү тәртибе турында методик тәкъдимнәрне раслау хакында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 23 ноябрендәге 1112 номерлы карары белән, саклау хезмәтләре бәясе нормативларын агымдагы базар шартларына туры китерү максатларында һәм хосусый саклау оешмалары хезмәтләре бәясен мониторинглау нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «2026 елга хосусый сак оешмаларыннан сатып алуларны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле хезмәт күрсәтүләрнең норматив бәясен җирле бюджет акчалары исәбеннән арттыру турында 2025 елның 26 декабрендәге 1527 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының җирле бюджеты акчалары исәбеннән 2026 елга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) хосусый саклау оешмаларыннан сатып алуларны гамәлгә ашырганда террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле саклау хезмәтләренең бер пост-сәгатенең норматив бәясен 300,0 сумга кадәр арттырырга.».

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль мәгариф оешмаларының хәвефлелекнең өченче категориясенә кертелгән объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле саклау хезмәтләрен сатып алуга әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән норматив нигезендә өстәмә финанслау тәэмин итәргә.

3. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларының хәвефлелекнең өченче категориясенә кертелгән объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүгә бәйле саклау хезмәтләрен әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән норматив нигезендә сатып алырга.

4. Әлеге карар 2026 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин